| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.09.2019 №1152

Опека һәм попечительлек органының
аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы
оешмалар эшчәнлеген тикшерү
тәртибен раслау турында

“Опека һәм попечительлек турында”гы 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек эшләрен башкаруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында”гы 2019 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы боерыгы , “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” гы 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерүне булдыру тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта).

2. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерү планын расларга (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече Э.Ф. Баһмановага йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________

карары белән
РАСЛАНГАН

**Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерүне булдыру тәртибе турындагы**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

**1. Гомуми нигезләмәләр.**

1.1. Әлеге тәртип “Опека һәм попечительлек турында”гы 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенең 24 пункты белән расланган,Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 235 номерлы боерыгы белән расланган, Балигъ булмаган балаларга карата, мәгариф оешмалары, медицина оешмалары,социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар яки башка оешмалар, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмалар тарафыннан,опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 5 пунктын үтәү максатларында эшләнгән. Шулай ук бу тәртип , балигъ булмаган гражданнарның опекун яки попечительләре булырга яки ата - ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең башка гаилә законнарында билгеләнгән формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органы вәкаләтен тапшыру турында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән төзелгән шартнамәләре булган оешмаларның эшчәнлеген тикшерүне үтәү кагыйдәләрен билгели (алга таба-опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләте).

1.2. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек эшләрен башкаруның аерым мәсьәләләрен гамәлгә ашыру турында”гы 2019 елның 10 гыйнварындагы 4 номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә, опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерүдә тоту, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы тарафыннан башкарыла.

1.2.1. Әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла торган тикшерү предметы булып түбәндәгеләр тора:

1.2.2. Оешмалар тарафыннан гражданнарны әзерләү буенча укыту-тематик планның үтәлеше.

1.2.3. Гражданнарны әзерләү дәрәҗәсенә карата таләпләрнең үтәлеше.

1.2.4. Гражданнарга әзерлек программасын узу турында документлар бирүнең нигезлелеге.

1.2.5 Балигъ булмаган гражданнарның опекун яки попечительләре булырга яки ата - ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең башка гаилә законнарында билгеләнгән формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарның әзерлеген тикшерү технологияләре куллану.

1.2.6. Балигъ булмаган балаларның опекун яки попечительләре булырга яки ата - ана каравыннан мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең башка гаилә законнарында билгеләнгән формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарның әзерлек тәртибенең, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасы эчтәлегенә карата таләпләрне һәм Россия Федерациясе территориясендә мондый әзерлек узу турында таныклык рәвешләрен раслау турында”гы 2012 елның 20 августындагы 623 номерлы боерыгы белән расланган - ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү программасы эчтәлегенә карата таләпләргә туры килүе.

1.3. Тикшерүнең төп максатлары:

1.3.1. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешма эшчәнлегенең опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен түләүсез гамәлгә ашыру өлешендәге нәтиҗәләрен бәяләү.

1.3.2. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлегенең сыйфатын раслау.

1.3.3. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча сыйфатсыз эшчәнлекне ачыклау, аны бетерү буенча рекомендацияләр эшләү яки оешма белән шартнамәне өзү турында карар әзерләү.

1.3.4. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат базасын формалаштыру.

1.4. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлеген контрольдә тоту, мондый оешманың эшчәнлегенә карата тикшерүләр үткәрү ярдәмендә башкарыла.

**2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлегенә карата тикшерүләр үткәрү регламенты.**

2.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлеген тикшерү ,“Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”гы 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек буенча вәкаләтле вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.2. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлеген тикшерү, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

2.3. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

2.3.1. Планлы тикшерү булып,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган һәм әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә формалашкан тикшерүләр планына кертелгән тикшерү тора.

2.3.2. Бер оешманы планлы тикшерү, килешү нигезендә, балигъ булмаган балаларның опекуннары һәм попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны әзерләү өчен юллама бирелгән очракта елга бер тапкыр үткәрелә.

2.3.3. Планлы тикшерү оешманың урнашу һәм эшчәнлек алып бару урыны буенча (урынга чыгып тикшерү) үткәрелә.

2.4. Тикшерүләр планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү була.

2.4.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечительлек органы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә:

- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашырганда, гражданнар ,оешма тарафыннан аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турындагы шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә;
- Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, башка оешмалар һәм гражданнар, массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан, оешма эшчәнлегендә опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашыруда гамәлдәге закон нормаларын бозу очраклары булу турында мәгълүмат килгәндә.

Планнан тыш тикшерү урынга чыгып яки урынга чыкмыйча, бу пунктта күрсәтелгән очраклар туганда, чикләнмәгән күләмдә үткәрелә.

2.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшергәндә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзаларының:

- әлеге вәкаләтне гамәлгә ашыруга карамаган гамәлдәге законнар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;
- тикшерү предметына кагылмаган документлар, мәгълүмат тапшыруларын таләп итәргә;
- элеге тәртиптә күрсәтелгән вакыттан да озаграк тикшерү үткәрергә хокуклары юк.

2.6. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда оешма эшчәнлегенә карата планлы (планнан тыш) тикшерү уздыру максатларында, вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр),тикшерү үткәрү турында түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмати хатны җибәрүне тәэмин итә:

2.6.1. Опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан бирелә торган хисапларны килешүдә билгеләнгән срокларда анализлау.

2.6.2. Опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы оешмалардан кирәкле мәгълүмат, документлар һәм аңлатмалар соратып алу.

2.6.3. Аерым вәкаләтне гамәлгә ашыру буенча оешмаларның эшчәнлеген анализлау һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү яки әлеге вәкаләтне туктату буенча тәкъдимнәр кертү.

2.6.4. Аерым вәкаләтне гамәлгә ашыру буенча оешмалар эшчәнлегенә күчмә тикшерүләр уздыру, шул исәптән оешманың ел саен вәкаләтле орган тарафыннан расланган планнары нигезендә, оешмаларның гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча хезмәтләрне планлы тикшерүләр рәвешендә күрсәтү процессын, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү буенча планнан тыш тикшерүләр үткәрүне күзәтү.

2.6.5. Оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдаланучыларны анкеталау формасында сораштыру.

Тикшерү үткәрү турындагы мәгълүмати хат, оешмага, тикшерү башланганчы 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзаларының:
- тикшерү максатына ирешү өчен кирәкле барлык документларны (мәгълүматны) соратып алырга, шулай ук тикшерү барышында килеп чыккан мәсьәләләр буенча язмача һәм телдән аңлатмалар таләп итәргә;
- тикшерү материалларына кушу өчен тикшерү предметына кагылышлы документларның күчермәләрен алырга хокуклары бар.

2.8. Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеге карата планлы (планнан тыш) тикшерүне урынга чыгып уздыруның гомуми срогы 2 эш көненнән дә артырга тиеш түгел.

2.9. Күчмә тикшерү тәмамланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, оешманың вазыйфаи затларының материалларын, документларын һәм аңлатмаларын өйрәнү нәтиҗәләреннән чыгып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты(муниципаль хезмәткәрләрнең) яисә комиссия

тарафыннан тикшерү акты төзелә һәм опека- попечительлек органының аерым вәкаләтләрен башкаручы оешманың җитәкчесе һәм гамәлгә куючысына җибәрелә.

Тикшерүне үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан, белешмәдә, күрсәтелә торган хезмәт сыйфатының гамәлдәге закон таләпләренә һәм муниципаль хокукый актларга туры килү-килмәвенә бәя бирелә һәм билгеләнгән эшчәнлек күрсәткечләрен һәм дәрәҗәсен бәяләүне исәпкә алып,оешманың алдагы эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр чагылдырыла.

2.9.1. Субъект эшчәнлегендә җитешсезлекләр булу яки үтәү өчен мәҗбүри булган таләпләрне бозу очраклары ачыкланса, вәкаләтле орган, аларны үтәү срокларын күрсәтеп, оешмага ачыкланган бозуларны бетерү турында тәкъдим җибәрә.

2.9.2. Тәкъдим җибәрелгән оешма аны билгеләнгән срокта үтәргә һәм документлар белән бергә тәкъдимнең үтәлеше турында хисап тапшырырга тиеш.

2.9.3. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә.

2.9.4. Тикшерү акты үз эченә түбәндәге мәгълүматларны алырга тиеш:

- тикшерү актын төзү датасы, тикшерү үткәрү көннәре санын күрсәтеп, урыны һәм срогы турында;
- тикшерү төре һәм формасы турында;
- тикшерү үткәрүгә карата чыгарылган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты карарының датасы һәм номеры;
- тикшерү үткәрелгән оешманың исеме турында;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә тикшерү үткәрүче комиссия әгъзалары турында (комиссия рәисе күрсәтмәсе белән);
- тикшерү үткәрү өчен оешма тарафыннан тапшырылган (тапшырылмаган) Документлар (мәгълүмат) турында;
- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен тормышка ашырганда оешма эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозу фактлары, аларның характеры һәм эчтәлеге турында;
- опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлегендә ачыкланган бозуларны һәм җитешсезлекләрне тикшерү тәмамланган вакытка бетерү турында;
- тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм йомгаклар;
- оешма җитәкчесен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырудан баш тарту яки таныштыру турында мәгълүматлар.

2.9.5. Тикшерү акты Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Тикшерү актына кул кую мөмкинлеге булмаган очракта, тикшерү актында, комиссиянең аерым әгъзалары тарафыннан, тиешле имза булмау сәбәпләре күрсәтелеп, билге куела.

2.9.6. Тикшерү актына тикшерүгә кагылышлы документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән ачыкланган бозулар өчен җавап бирүче оешма вазыйфаи затларының аңлатмалары теркәлә.

2.9.7. Тикшерү актының бер нөсхәсе, оешма җитәкчесенә, Башкарма комитет җитәкчесе раслаганнан соң, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.9.8. Урынга чыкмыйча тикшерү, Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәрләренә), яисә комиссия

тарафыннан булган документларны, шулай ук оешмадан соратып алына торган документларны, оешманың вазыйфаи затларының аңлатмаларын карау юлы белән үткәрелә.

2.9.9. Тәкъдим җибәрелгән оешма җитәкчесе аны билгеләнгән ай эчендә үтәргә һәм документлар белән бергә тәкъдимнең үтәлеше турында хисап тапшырырга тиеш.

2.9.10. Тикшерү йомгаклары буенча Башкарма комитет тикшерү нәтиҗәләре турында акт әзерли. Белешмә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Белешмә, аны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе килештергәннән соң, 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча заказлы хат белән оешмага җибәрелә.

## 3. Опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча оешмалар эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре.

3.1. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, оешманың эшчәнлеге гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актларга туры килүе турында яки опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма белән шартнамәне өзү турында Карар кабул ителә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________________________

карары белән расланган

Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген тикшерүне булдыру тәртибе турындагы нигезләмәгә 1 кушымта

**Балигъ булмаган балаларның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясенең Гаилә законнарында билгеләнгән башка формаларда гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтен гамәлгә ашыручы оешма эшчәнлеген**

## ТИКШЕРҮ ПЛАНЫ

| Тикшерүләр күләме | Тикшерү үткәрү ае | Тикшерү үткәрү датасы | Тикшерү үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| Елга бер тапкыр | Ноябрь | Айның дүртенче атнасы | Ике көн |

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов